**«Яшел Үзән диләр безнең якны...»**

**Мулла Иле мәктәбе укытучысы Гыйбадуллина Элиза Фаварис кызы**

**Тема:** «Яшел Үзән диләр безнең якны...» (Равил ага Сәйфетдинов иҗатына нигезләнеп, туган якны өйрәнү буенча сыйныф сәгате.)

**Максат:** 1. Туган тел, туган як белән горурлану хисе уяту, аның матурлыгын тоярга өйрәтү, миллилек тәрбияләү; Россиядә, Татарстанда яшәүче милләтләрнең дуслыгына хөрмәт булдыру.

2. Туган авылны ярату хисен уяту.

3. Үз авылыбызның талант иясе Равил Сәйфетдинов иҗаты белән якыннан таныштыру.

**Җиһазлау:** Равил Сәйфетдинов портреты, әсәрләреннән төзелгән китап күргәзмәсе, мультимедиа, әсәрләренә укучылар ясаган рәсемнәр, матбугат материаллары.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше.**

Дәресне алып бару өчен уңай психологик халәт тудыру.

Укытучы. Исәнмесез, укучылар! Әйдәгез, матур итеп сәламлик әле бер-беребезне, каршыда һәм күршедә утыручы дусларыгызга, ягымлы елмаеп, сәлам юллыйк. Барыбызның да кәефе күтәрелеп китте. Дусларым, дәрес буена күтәренке кәеф, елмаю безне ташламас дип ышанып калам.

**II. Актуальләштерү.**

*Р.Сәйфетдиновның «Тау ягы» шигыре (бер укучы сөйли, талгын көй).*

Укытучы. Туган як, туган туфрак, туган якның сихри табигате... Шундый кадерле, якын һәм назлы бу сүзләр. Иң беренче тапкыр бу дөньяга аваз салган, тәпи йөреп киткән вакытыбыздан алып, гомер агышы дәвамында бу изге сүзләр безне иркәли, назлый, сөя.

Һәркем өчен үзенең туган авылы, җанына рәхәтлек бирә торган гүзәл табигате, шифалы сулары бик тә газиз. Менә шуңа күрә язмышка ияреп, читләргә чыгып киткән кеше дә, авыр вакытта туган ягына кайтып сыена.

Туган туфракның әреме дә, миләше-мәтрүшкәсе дә синең күңелеңә дәва бирә, яшәү көче өсти, киләчәккә омтылыш тудыра. Һәр якның матурлыгы, гүзәллеге иҗат әһелләре әсәрләре аша әдәбиятка үтеп керә, башкаларны да таң калдыра, сокландыра.

Иҗат әһелләре дигәч, күз алдына якташларыбыз – Каюм Насыйри, Афзал Шамов, Идрис Туктар, Азат Вергазов, Шәриф Сайкин, Гомәр Саттаров, Резидә Төхвәтуллина, Рәшид Кәлимуллин килә. Авылыбызның шагыйре, аксакалы Равил абый Сәйфетдинов та шушы исемнәр белән янәшә торырга хокуклы. *(Портретлары экранда күрсәтелә бара.)*

**III. Яңа материал белән танышу.**

Укытучы. Укучылар без нинди илдә яшибез? *(Россиядә.)* Без борынгы бабаларыбыздан искиткеч матур илне мирас итеп алдык. Россия тарихы меңнән артык ел белән исәпләнә. Гасырлар буена Россиядә яшәүче барлык халыклар, бик күп буын кешеләре аны ныгытканнар һәм саклаганннар, Россиянең куәтен һәм мәдәниятен үстергәннәр.

«Россия» атамасы бик борынгыдан килә. Илебезнең икенче исеме – «Россия Федерациясе». «Федерация» сүзенең латинчадан тәрҗемәсе «союз, берләшү» дигән мәгънәне аңлата. Россия территориясендә 100 дән артык милләт яши: руслар, татарлар, бурятлар, якутлар, башкортлар, калмыклар, аварлар, ингушлар, балкарлар, кареллар, урдмуртлар, ненецлар, эвенклар һәм башка бик күп халыклар. Барысын да санап бетерер өчен бик күп вакыт кирәк булыр иде.

*Р.Сәйфетдиновның «Хөр бул, Рәсәй!» шигыре (бер укучы сөйли).* ***(4 нче слайд).***

Укытучы. Укучылар, без яшәгән республика ничек дип атала? *(Татарстан Республикасы.)* Татарстан – иң бай һәм мәйданы ягыннан да шактый зур республикаларның берсе. Татарстанда 173 милләт вәкиле яши. Төрле-төрле чәчәкләрдән торан гүзәл чәчәк бәйләме кебек, Республикабыз да күпмилләтле булуы һәм ул милләтләрнең үзара дуслыгы белән бик күркәм.

*Р.Сәйфетдиновның «Татарстан» шигыре (бер укучы сөйли).* ***(5 нче слайд).***

Укытучы. Татарстан Республикасында 43 район бар. Безнең районның исеме – Яшел Үзән – үзенең җисеменә бик тә туры килеп тора. Яшел Үзән шәһәре Казаннан 40 км ераклыкта урнашкан. Җәен ул яшеллеккә төренеп утыра, шуңа күрә аны Яшел Үзән дип йөртәләр. Шәһәр үзенең зурлыгы буенча Татарстан калалары арасында бишенче урында тора. Район чиге ике республика – Марий Эл һәм Чувашстан белән тоташкан. *(Картадан күрсәтү).*

*Р.Сәйфетдиновның «Зеленодольск» шигыре (бер укучы сөйли).* ***(6 нчы слайд).***

*Фонда поезд тавышы яңгырый.*

*Җыр. «Чаба поезд, чаба» («Саубуллашу»).*

*Р.Сәйфетдиновның «Яшел үзән» шигыре (бер укучы сөйли).* ***(7 нче слайд).***

Укытучы. Туган як, туган туфрак... Кешене үзенә бәйләгән, кая гына китсә дә, гомере буе сагындырып, үзенә чакырып тора торган изге җир! Туган якка булган мәхәббәт хисләре вакытлар үтү белән тирәнәя, тулылана гына бара.

Туган авыл... Йөрәккә иң якын һәм кадерле сүз. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, йортыбыз урнашкан кадерле туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас, кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Сокланып туймаслык тугайлар, челтерәп ага торган чишмә буйлары, балыклы күлләре, куе әрәмәләр белән уратылган елга үзәннәре, басулары, шаулап торган урманнары күңелгә рәхәтлек биреп, туган авылга мәхәббәт хисе уята. Кая гына барсак та, туган авылның матурлыгын берни дә алмаштыра алмый. Аның һәр сукмагы күңелгә якын.

Бер ягында биек таулар җәйрәп яткан, икенче ягында болыннар җәелеп киткән, елга ярларында камышлар һәм таллар үсеп утырган авылыбызның исеме – Мулла Иле. Ямьле Мулла Иле Яшел Үзән районында, район үзәгеннән – 33, Албаба тимер юл станциясеннән 3 чакрым ераклыкта урнашкан. Тылсымлы-сихри табигате, урман-кырлары, болын-чалулары, елга-күлләре белән матур ул. Авылыбыз шагыйре, әти-әниләрегезнең остазы

булган Равил ага Сәйфетдинов аны юкка гына бәхет үзәне белән чагыштырмаган.

*Р.Сәйфетдиновның «Бәхет үзәне» шигыре* *(бер укучы сөйли).* ***(8 нче слайд).***

Укытучы. Менә бит шагыйрь ничек горурланып яза туган авылы, туган ягы турында! Равил абыйның шигырьләре – ул авылыбыз халкының күңел көзгесе. Шигырьләрендә шагыйрь җаны табигать җаны белән берләшә. Туган җирнең матурлыгын бары тик аның табигате аша гына күз алдына китерергә мөмкин. Табигать – Равил аганың илһам, яшәү чыганагы, яшәеш үрнәге. Шигырьләрендә шагыйрь күңеле язын кошлар белән туган якка кайта, җәен сандугачтай сайрый, көзен сагышларын кыр казының канатына элеп җибәрә, ә кышын ап-ак кар булып ява.

Әйдәгез, укучылар, Равил абыйның Мулла Иле. авылыбызның төрле ел фасылларында төрле рәвешкә кергән табигатенә багышланган шигырьләре белән танышып үтик әле. *(Укучылар шигырьләр сөйлиләр).*

*Р.Сәйфетдиновның «Авылым җәе» шигыре*. ***(9 нчы слайд).***

*Р.Сәйфетдиновның «Туган кырларым» шигыре*. ***(10-11 нче слайдлар).***

*Р.Сәйфетдиновның «Әрә белән Зөя» шигыре*. ***(12 нче слайд).***

*Р.Сәйфетдиновның «Алтын көзем» шигыре*. ***(13 нче слайд).***

*Р.Сәйфетдиновның «Кар яктысы» шигыре*. ***(14 нче слайд).***

*Р.Сәйфетдиновның «Күңелемдә язлар тулы» шигыре*. ***(15 нче слайд).***

**lV. Ныгыту.**

Укытучы. Рәхмәт, укучылар. Менә шундый гүзәл табигать язучыга үзенең илаһи көчен биргән. Равил абыйның, кайсы гына шигырен алма, һәммәсендә туган якка мәхәббәт, соклану, горурлану ярылып ята. Укучылар, әйдәгез бергәләп, авылыбыз гимны булып яңгырарлык «Мулилем» җырын башкарып үтик. Равил абыйның әлеге шигыренә композитор Риф Гатауллин бик матур көй язган.

*Җыр. «Мулилем».* ***(16 нчы слайд).***

*Р.Сәйфетдиновның «Мулла Иле» шигыре* *(ике-өч укучы шигырь сөйләгән вакытта Мулла Иле авылы аэросъемкада күрсәтелә).*

**V. Дәресне йомгаклау.**

Укытучы. Әйе, гадәти тормыш агышы нәкъ менә шулай дәвам итә, ләкин зур талант ияләренә мондый язмыш янамый. Андый затлар дөньялыкта нинди иҗади югарылыкка ирешкән булсалар, гүр иясенә әйләнгәннән соң да, даннарына зыян килми. Сез - Равил ага варислары, аның авылдашлары. Равил абый Сәйфетдинов шигырьләре – аның сезгә туган авылны яратырга, сакларга «кушкан» васыяте, ә васыятьне, һичшиксез, үтәргә кирәк.

Укучылар, буш вакытларыгызны әрәмгә уздырганчы, якташ язучыларыбызның иҗат дөньясына үтеп кереп, серләр дөньясында канатланыйк һәм үзебезнең як табигате сулышын, туфрагының җылысын тоеп, яшәүнең тәмен һәм мәгънәсен сизеп яшик. Ә без бу серләргә бары тик якташларыбыз иҗаты белән кызыксынганда, тарих, әдәбият дәрьясында йөзгәндә генә төшенә алабыз.

Шуның белән сыйныф сәгатебез тәмам. Игътибар белән карап утыруыгыз, катнашуыгыз өчен рәхмәт.

**Кулланылган әдәбият**

1. Сәйфетдинов Р.Г. Аксакал язмалары. Шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр җыентыгы.// Казан, 2017.

2. Сәйфетдинов Р.Г. Кичке шәфәкъ. Шигырьләр җыентыгы.// Казан, 2001.

3. Сәйфетдинов Р.Г. Мулла Иле моңнары. Шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр җыентыгы.// Казан, 2010.

4. Хәмидуллина Р.Г., Габделхәева Г.Б. Илһам биргән җирем.// Казан, 2020.